■ Ислам кагыйдәләре

# ИЗГЕ РАМАЗАННАН ИМАН НУРЫ АЛЫЙК!

### УРАЗАНЫҢ ТӨРЛӘРЕ

Ураза фарыз, ваҗиб, нафилә (нәфел) һәм мәкруһ дигән дүрт төргә бүленә.

Рамазан бәйрәменең беренче көнендә, Корбан бәйрәменең дүрт көнендә ураза тору мәкруһтыр (ягъни, тыелмаса да, хуп күрелми), чөнки бу көннәр Аллаһы Тәгаләнең колларына ихсан иткән зыяфәт көннәредер. Бәйрәм зыяфәтеннән качу яхшы түгел.

### ШӘҮВӘЛДӘ АЛТЫ КӨН УРАЗА

Шәүвәл аенда атнага ике көн (тоташ түгел), җәмгысы алты көн ураза тоту мөстәхәбтер. Икенче яктан, алты көн тоташ ураза тоту да хата саналмый.

### УРАЗАНЫҢ ШАРТЛАРЫ

Уразаның шартлары вөҗүб һәм әда шартлары дигән өлешләргә бүленә.

Вөҗүб шартлары: мөселман булу, акыллы һәм балигъ булу. Кеше бу сыйфатларның берсеннән мәхрүм генә булса да, аңа ураза тоту фарыз түгел.

Әда шартлары: сау-сәламәт булу, өйдә тоту, ният кылу һәм хәез-нифастан (күремнән) пакь булу.

Шулай ук чирле белән юлчы кешеләр өчен ураза тоту фарыз түгел. Алар авырган чакта яки сәяхәт вакытында калдырган уразаларын соңрак каза кылырлар.

Ният әда шартлары арасында бик әһәмиятле урын били. Ният итмичә тотылган ураза чын ураза булып саналмый.

### УРАЗАНЫҢ ВАКЫТЫ

Уразаның вакыты - таң атудан (ягъни кояшның кызыллыгы сизелә башлаганнан) алып кояш баешына кадәр дәвам иткән мөддәт.

### УРАЗАНЫҢ НИЯТЛӘРЕ

Уразаның теләсә нинди төренә дә калеб белән ният итү җитәрлек санала. Ураза вакытында сәхәргә тору да бер нияттер. Тел белән ният итү дә диндә яхшы дип санала.

Рамазан уразасы, билгеләнгән нәзер һәм нәфел уразасы өчен ният кылу вакыты, кояшның баешыннан алып иртәгесе көннең өйләсенә кадәр дәвам итә.

Рамазан уразасының һәр көне өчен аерым ният ителә, чөнки арага төннәр керә. Аннан соң, көннең уразасы - мөстәкыйль бер гыйбадәттер. Шуның өчен бер көн ураза бозылса да, башка көннәргә тәэсире юк.

### УРАЗАЛЫ КЕШЕ ӨЧЕН МӨСТӘХӘБ ЭШЛӘР

Ураза тотучы кешенең сәхәр ашына торуы мөстәхәбтер. Сәхәр ашын төн бетәр алдыннан ашыйлар. Ягъни сәхәрне никадәр кичектерсәң, шулкадәр әйбәт. Әлбәттә, таңның белеүенә кадәр бик аз вакыт калмасын.

Ифтар ашын мөмкин кадәр




тизрәк, ягъни ахшам намазыннан элек ашау мөстәхәбтер. Шулай иткәндә, ачлык тойгысы намазга комачау итмәс.

Авыз ачканчы мондый догаль уку сөннәттер: "Аллаһүммә ләкә сумтү вә бикә әмәнтү вә галәйкә тәвәккәлтү вә галә ризыйкә әфтартү вә саумәлгади мин шәһри рамазанә нәвәйтү. Фәгъфирли ма каддәмтү вә ма аххәртү" (Аллаһым, синең ризалыгың өчен ураза тоттым. Сиңа иман иттем, Сиңа тәвәккәл иттем, үзеңә ышанып тапшырдым, Синең ризыгың белән авызымны ачтым. Рамазан аеның иртәгесе көне өчен ураза тотарга ният иттем. Кылган һәм кыласы гөнаһларымны ярлыка).

Авызыны хөрмә кебек баллы ризыклар белән ачу мәгъкуль, яхшы санала.

Ураза тоткан кешенең якыннарына һәм фәкыйрьләргә гадәттәгесенә караганда күбрәк ярдәм итүе мөстәхәбтер.

Уразалы кеше мөмкин кадәр көндез һәм кичен Коръән укыса, зикер итсә, Пәйгамбәребезгә (с.г.в.) салават китерсә, гыйлем белән шөгыль итсә, бу гамәлләре мөстәхәб булыр.

Уразалы кешенең буш һәм мәгънәсез сүзләр сөйләүдән тыелуы да мөстәхәбтер. Гайбәт таратудан, сүз йөртүдән качу исә һәрвакыт ваҗибтер. Тик моның әһәмияте Рамазан аенда аеруча зур була.

### УРАЗА ТОТКАНДА МӘКРУҺ ҺӘМ МӘКРУҺ БУЛМАГАН ЭШЛӘР

Уразалы кешенең суга чылатылган теш чистарткычы кулланыу, Имам Әбү Йосыф фикеренчә, мәкруһтыр. Әмма башка галимнәрнең сүзенә караганда, иртән яки кояш баткаңнан соң коры һәм теш чистарткычы куллануда кәраһәт юк.

Уразалы кешенең истинҗа вакытында (олы тәһарәт алганда) артык күп итеп су куллануы мәкруһтыр. Тәһарәттә авызына яки борынына кирәгеннән артык су алуы мәкруһтыр.

Ураза иясенең үзен акларлык бер сәбәбе дә булмыйча пешкән ризыкны авыз итеп каравы мәкруһтыр. Әгәр инде берәр хатын-кызның ире бик холыксыз икән, ул вакытта әлеге хатын пешергән әйбернең тозлы-тозсыз яки баллы-балсыз булып пешкәнен белер өчен, аны йотмау шарты белән авызга алырга мөмкин.

Үз-үзенең ныклыгына ышанмаган ураза иясенең хатынын үбүе һәм назлавы мәкруһтыр.

Уразалы кешенең хатыны белән икесе ялангач хәлдә кочаклашулары һәр очракта (ягъни ир кеше үзенең хатыны белән җенси мөнәсәбәткә кермәячәгенә ышанган тәкъдирдә дә) мәкруһтыр. Хатынының иреннән суырып үбү шулай ук мәкруһ. Уразалы кеше хуш исле чәчәкләрне иснәсә, сөрмә тартса, мыек кремы (мае) кулланса, мәкруһ түгел.

---

Өфөлә намаҙ ваҡыты

**Рамаҙан 2011 миләди йыл**
**1432 һижри йыл.**

| Рамаҙан | Аҙна көндәре | Август | Иртәнге намаҙ | Ҡояш сыға | Өйлә нам. | Икен. нам. | Аҡшам. | Йәстү намаҙы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Дүшәмбе | 1 | 4.27 | 4.57 | 14.30 | 20.46 | 22.16 | 00.15 |
| 2 | Шишәмбе | 2 | 4.29 | 4.59 | 14.30 | 20.44 | 22.14 | 00.15 |
| 3 | Шаршамбы | 3 | 4.31 | 5.01 | 14.30 | 20.42 | 22.12 | 00.10 |
| 4 | Кесе йома | 4 | 4.32 | 5.02 | 14.30 | 20.40 | 22.10 | 00.10 |
| 5 | Йома | 5 | 4.34 | 5.04 | 14.30 | 20.38 | 22.08 | 00.05 |
| 6 | Шәмбе | 6 | 4.36 | 5.06 | 14.30 | 20.36 | 22.06 | 00.05 |
| 7 | Йәкшәмбе | 7 | 4.38 | 5.08 | 14.30 | 20.34 | 22.04 | 00.05 |
| 8 | Дүшәмбе | 8 | 4.40 | 5.10 | 14.30 | 20.32 | 22.02 | 00.00 |
| 9 | Шишәмбе | 9 | 4.41 | 5.11 | 14.30 | 20.30 | 22.00 | 00.00 |
| 10 | Шаршамбы | 10 | 4.43 | 5.13 | 14.30 | 20.28 | 21.58 | 00.00 |
| 11 | Кесе йома | 11 | 4.45 | 5.15 | 14.30 | 20.26 | 21.56 | 23.55 |
| 12 | Йома | 12 | 4.47 | 5.17 | 14.30 | 20.24 | 21.54 | 23.55 |
| 13 | Шәмбе | 13 | 4.49 | 5.19 | 14.30 | 20.22 | 21.52 | 23.50 |
| 14 | Йәкшәмбе | 14 | 4.50 | 5.20 | 14.30 | 20.20 | 21.50 | 23.50 |
| 15 | Дүшәмбе | 15 | 4.52 | 5.22 | 14.30 | 20.17 | 21.47 | 23.50 |
| 16 | Шишәмбе | 16 | 4.54 | 5.24 | 14.30 | 20.15 | 21.45 | 23.45 |
| 17 | Шаршамбы | 17 | 4.56 | 5.26 | 14.30 | 20.13 | 21.43 | 23.45 |
| 18 | Кесе йома | 18 | 4.58 | 5.28 | 14.30 | 20.11 | 21.41 | 23.40 |
| 19 | Йома | 19 | 5.00 | 5.30 | 14.30 | 20.08 | 21.38 | 23.40 |
| 20 | Шәмбе | 20 | 5.01 | 5.31 | 14.30 | 20.06 | 21.36 | 23.35 |
| 21 | Йәкшәмбе | 21 | 5.03 | 5.33 | 14.30 | 20.04 | 21.34 | 23.35 |
| 22 | Дүшәмбе | 22 | 5.05 | 5.35 | 14.30 | 20.01 | 21.31 | 23.30 |
| 23 | Шишәмбе | 23 | 5.07 | 5.37 | 14.30 | 19.59 | 21.29 | 23.30 |
| 24 | Шаршамбы | 24 | 5.09 | 5.39 | 14.30 | 19.57 | 21.27 | 23.25 |
| 25 | Кесе йома | 25 | 5.11 | 5.41 | 14.30 | 19.54 | 21.24 | 23.25 |
| 26 | Йома | 26 | 5.12 | 5.42 | 14.30 | 19.52 | 20.22 | 23.20 |
| 27 | Шәмбе | 27 | 5.14 | 5.44 | 14.30 | 19.49 | 20.19 | 23.20 |
| 28 | Йәкшәмбе | 28 | 5.16 | 5.46 | 14.30 | 19.47 | 20.17 | 23.15 |
| 29 | Дүшәмбе | 29 | 5.18 | 5.48 | 14.30 | 19.45 | 20.15 | 23.15 |

# КАДЕР КИЧӘСЕ - ХӨКЕМ КИЧӘСЕ

Нәби-и-Мөхтәрәм (с.г.в.) Кадер кичәсен Рамазан аеның егерменче көненнән соңгы кичәләрдә булуын әйткән. Риваятьләр буенча, Кадер кичәсенең күбесенчә рамазанның 27нче кичәсенә туры килүе ихтимал ителәдер.

"Кадер" сүзе мөселман галимнәре тарафыннан өч төрле аңлатыла:

1. Кадер кичәсе - хөкем кичәсе. Ягъни бу билгеләмә буенча, Кадер кичәсендә "Илаһи тәкъдирдә хөкем кылынган эшләр һәм илаһи әмерләр тәгаенләнә".

2. Кадер кичәсенең мәгънәсе - "шәрәф һәм олуглыктыр". Ягъни, бу мәгънәгә караганда. Кадер кичәсе - бик шәрәфле (кадерле) һәм бик кыйммәтле кичә.

3. Кадер сүзе "кысылу" мәгънәсенә ия. Бу караш буенча, Кадер кичәсендә Җиргә иңгән фәрештәләргә Җир йөзе тар булып тоелыр.

### "КАДЕР" СҮРӘСЕНЕҢ МӘГЪНӘСЕ

"Кадер" кәлимәсе Җәнабе Хак тарафыннан Коръәндә бер сүрәгә исем итеп бирелгән. Сүрәнең мәгънәсе болай: "Чыннан да, без аны (Коръәнне) Кадер кичәсендә индердек, Кадер кичәсенең (олуг шәрәфен) сиңа белдергән нидер. Кадер кичәсе мең айдан хәерледер. Анда фәрештәләр вә Рух Раббыларының рөхсәте илә һәрбер эш өчен (җиргә) иңнеп торыр. Ул кичә таң беленгәнчегә кадәр сәлам кичәседер".

### КОРЪӘН КӘРИМ ИҢГӘН КИЧӘ

Кадер кичәсенең кыйммәте вә кадере бинийһа, бихисаптыр. Бу кичәдә Пәйгамбәребезгә (с.г.в.) индерелә башлаган Коръән Кәрим - Ходай тарафыннан бирелгән бакый могҗизадыр. Коръәннең тиңдәшсезлеге, могҗизалыгы кыяматкәчә дәвам итәр.

Кешенең йөрәге Коръән белән нурланыр, сөенер, калебе Коръәннең нечкә һәм гали мәгънәләре белән куәтләнер, зиһене көчәер. Коръәнне укымаган, тыңламаган кешенең калебе хәрабәгә әйләнгән өйгә охшап калыр. Шулай булгач, Коръәнне яратыйк, укыйк, укытыйк, укыганны тыңлыйк! Коръән аятьләренең тирән мәгънәсен өйрәнергә тырышыйк!

### КАДЕР КИЧӘСЕН НИЧЕК ҮТКӘРЕРГӘ?

Күзебезнең, күңелебезнең сафлыгы сөекле Пәйгамбәребез: "Кем Кадер кичәсен савабы булырына ышанып, ихлас күңелдән ихья итсә (гыйбадәт белән үткәрсә), шуның үткәндәге гөнаһлары ярлыканыр", - дип әйткән ("Риязес-салихин", II, 464, Бохари-Мөслим). Бу мөбарәк кичәне лаеклы рәвештә үткәрү өчен, түбәндәге киңәшләребезне тотарга тырышыгыз:

1. Кадер кичәсендә гыйбадәттә булырга, укылмаган намазларны каза кылырга, нафилә намазларын укырга кирәк.

2. Коръән Кәримне укырга, аны укыганнарны тыңларга кирәк.

3. Пәйгамбәребезгә салават әйтергә, аның шәфәгатен (яклавын, химаясен) өмет итәргә, аның өммәтеннән булуны яхшылап аңларга кирәк.

4. Вәгазь вә нәсыйхәт тыңларга, калебне билгән гафиллек томаннарын таратырга кирәк.

5. Кадер кичәсенә яки башка дини темаларга әңгәмәләр алып барырга кирәк.

6. Тәүбә вә истигъфар итәргә, нәфесеңне тикшерергә, хаталарны кабатламаска, тугры юлга басарга тырышырга кирәк.

7. Зикер итәргә, тирәнтен итеп уйланырга кирәк. Чөнки Аллаһы Тәгаләне зикер итү белән, калебләр тынычлыкка ирешә, кешедә иман куәтләнә.

8. Күп итеп дога укырга кирәк. Чөнки дога - бәндәләрне Җәнабе Хакка якынлаштыра торган иң гали чарадыр. Риваятьләр Пәйгамбәребезнең (с.г.с.) Кадер кичәсендә мондый дога укуын сөйли: "Аллаһүммә иннәкә гафүввун тухиббүл-гафвә фәгъфу анни" (Аллаһым! Син - гафу итүче, гафу итүне яратасың, мине дә гафу ит).

9. Кадер кичәсе көнен гыйбадәт белән үткәрү зур саваптыр.

10. Бу кичә хөрмәтенә Раббыбыздан бөтен мөселманнарны гафу итүен теләргә тиешбез. Кадер кичәсе хәерле эшләр кылу өчен форсат булсын, кардәшлек элемтәләрен ныгытсын. Ислам дөньясының берләшенә хезмәт итсен иде! Шул теләктә булыйк.

***"Инсан һәм дин" китабыннан алынды.***